Кеше язмышында анын яшьтэн ук нинди тэрбия алуы бик моһим. Тормышта уз урынын табарга сэлэтле, белемле, эшчэн, эхлаклы шэхес тэрбиялэу – ата-аналарнын һэм тэрбиячелэрнен топ бурычы. Кече яшьтэге балаларга рухи-эхлакый тэрбия бирудэ халкыбызнын гореф-гадэтлэрен, борынгыдан килгэн традициялэрен куллану унай нэтижэ бирэ. Мин узем шэхсэн, шушы балалар бакчасында олкэннэр торкемендэ эшлим. Узебезнен эшчэнлектэ Ризаэддин Фэхреддин мирасы аша балаларга анын нэсыйхэтлэрен мисал итеп ирештеругэ багышлап эш алып барам. Боек галим, тарихчы, педагог Р.Фэхреддиннен хезмэтлэре безгэ һэрдаим ярдэмгэ килэ. Узебезнен рухи-эхлакый тэрбия эшендэ мин анын нэсыйхэтлэрен, кыйммэтле кинэшлэрен, тэрбия хакындагы мэкальлэрен балаларга житкерергэ тырышам. Торкемебездэ милли йола, гореф-гадэтлэрен онытмау, барлау йозеннэн дэ куп эш башкарыла: гаилэ бэйрэмнэре, “Нэуруз”, “Сабантуй”, “Энилэр коне”, “Аулак ой” кебек бэйрэмнэр уздырыла. Галим сузлэре белэн эйтсэк: “һэр халыкнын узенэ хас традициялэре бар, яшь буынны шул традициялэрдэ тэрбиялэгэндэ генэ миллэт, шэхес усеше тээмин ителэ”.

Ризаэддин Фәхреддин бай рухи мирасы милли тәрбия бирүдә һәм әдәпкә өйрәтүдә зур хәзинә булып тора. Анда әхлакның бөтен яклары ярылып ята: кыз балалар әдәбе, колак, күз, кул, чәч әдәпләре, ир бала әдәпләре, үз-үзеңне тоту әдәпләре, хәтта мөгаллимлек, шәкертлек, хатын-кыз, ана, ата әдәпләре дә бар. Төркемебездә балаларга әхлак тәрбиясе бирү буенча халык мәкальләрен өйрәнүне аеруча кулланам. Көндәлек режимнарда, төрле халык уеннарында да Ризаэддин Фәхреддин киңәшләрен кулланып, әңгәмәләр вакытында балалар белән бу хакта фикер алышабыз.

Ризаэддин Фәхреддин халык педагогикасына мөрәҗәгать итеп, педагогик фикерләрне баетуда тәрбия чараларының, традицияләренең берсе – нәселеңне, буыннар чылбырыңны истә тоту дип фаразлый. Кеше, ата-бабалары, аларның эшләре белән горурланып, аларның исемнәренә тап төшермәскә тырышып яшәргә тиеш. Татарларда шәҗәрә төзү, гаилә ядкәрләрен кадерләп саклау күренеше киң таралган. Бу эшне без ата-аналар ярдәмендә башкарып чыктык, чөнки балалар бу эшне үзләре генә башкарып чыга алмый, әти-әниләр, әби-бабайлар, гомумән, шул нәселдә булган барлык мәгълүматлы кешеләр бу эштә бик кызыксынып һәм теләп катнашты. Ата-аналар да моңа буыннар арасындагы бәйләнеш, туганлык-кардәшлек хисләрен ныгыту чарасы итеп карады. Яшь буынның нәсел дәвамчысы, ыруг-кабилә, милләт-дәүләтнең киләчәге икәнен истә тотканда, аларның нәсел шәҗәрәләре белән кызыксынуы – бик кирәкле гамәл. Һәр шәхеснең, һәр

гаиләнең үз нәсел шәҗәрәсен төзүе – милләт каршындагы изге бурычы дип уйлыйм мин.

Ризаэддин Фәхреддин мирасын өйрәнгәндә мин балалар белән аның тәрбия китапларында чагылдырган нәсыйхәтләрен еш кабатлыйм. Ул тәрбия китапларында чисталык, төрле авырулар, ашау-эчү кагыйдәләре, сәламәтлек, тырышлык, өс һәм аяк киемнәре, үз-үзеңне тоту, милли традицияләргә ихтирам белән карау, сакчыл мөнәсәбәт һәм башкалар хакында мәгълүмат һәм киңәшләр бирә.

Әгәр дә без бүген рухи афәттән яшь буынны коткарырга теләсәк, газиз балаларыбыз бәхетле һәм дөрес тәрбия алсын дисәк, мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин бине Фәхреддиннең “Гыйлемнән башка – байлык, байлыктан башка гыйлем булмас. Ягъни гыйлемсез милләт баемас вә алга китмәс, баемаган милләт гыйлем өйрәнә алмас”, дигән сүзләрен истә тотып, гыйлемле, тәрбияле, иманлы балалар тәрбияләп үстерик дигән бурычны куярга тиешбез. “Без бетә торган кавем түгел, бәлки дөньяда мәңге торыр вә башка милләтләр белән бергә берлектә җир йөзеннән файдаланыр өчен килгән милләтбез”, - дип әйткән Ризаэддин Фәхреддин. Милләтне яшәтерлек буын тәрбияләү – һәрберебезнең изге эше, бурычы. Бөек шәхесне без генә түгел, киләчәк буын да онытмасын, аны өйрәнсен, аның хезмәтләрен куллансын һәм аның белән горурлансын иде! Безнең буынның өмете – балаларда, безнең максат – аларны иманлы итеп тәрбияләү. Шул вакытта гына үзебез дә әдәпле, милли үзаңлы, яхшы алмашчылар әзерли алырбыз.

Язмамны якташыбыз, олуг педагог Ризаэддин Фәхреддин язган сүзләр белән тәмамлыйсым килә: “Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә тәрбияле баладыр. Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер”.

Әлмәт шәһәренен №58 нче “Шаян нәниләр”

балалар бакчасы олкәннәр төркеме тәрбиячесе

Вәлиева Венера Әсгать кызы

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН
МЕМОРИАЛЬ МУЗЕЕ